

ЧАЯН

ISSN 0136-7110

САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ* ГЫЙНВАР * 2016 КАЗАН 2



Александр АЛЁШИН

АННАН-МОННАН

ИҢФОРМ

СОҢГЫ ХӘБӘРЛӘР

- Безнең депутатлар һәм түрәләр кыюлыклары белән бөтен дөньяга мәгълүмнәр. Алар үзләренең балаларын, бер дә курыкмыйча, педофиллар, зоофиллар һәм гейлар белән тулган Европага җибәрәләр.
- Лабуда-үзәк сораштырулары күрсәтүенчә, Татарстан дәүләт оешмаларында хезмәттә чакта мәхәббәт куертулар күзәтелми, чөнки андагы хезмәткәрләр бер-берсенә туганлык җепләре белән бәйләнгән.
- Ерак юлларга йөрүче шоферлар демонстрациясе администрация бинасындагы җыештыручы тарафыннан туктатылган, сәбәбе – "юылган җирдән" үтәргә ярамый.
- Елганы кичкән вакытта, суның уртача тирәнлеге бер генә метр булуга карамастан, статист батып үлгән.
- Быелгы елда иң популяр һөнәр рейтингы буенча югары баскычта "Газпром" җыештыручысы санала.
- Ямьсез кызлар, аракы сатуны 22 сәгатьтән соң да сатуга рөхсәт сорап, Интернетта имза җыялар.
- Иң кыйммәтле фотолар булып ЮХИДИдан килгән фотолар саналган.
- Инглиз галимнәре "айфон законы" ачканнар – ул һәрвакыт экраны белән аска төшә.
- Гиперпаркетның "Ит" бүлегеннән экологик чиста ит төргәге урланган. Ул анда ничек килеп эләккәнне хәзер полиция тикшерә.
- Югары уку йортының кабул итү комиссиясендә Бердәм Дәүләт имтиханнарын 100 баллга бирүчеләрне дагстанлылар дип атыйлар.
- Хастаханәнең баш табибы, постель режимын үтәмәгән өчен, сәркатип кызны эшеннән азат иткән.
- Шәһәр лифтларында уңайлы биобәдрәфләр барлыкка килүе мөмкин.
- Кышын кыска итәк һәм капрон колготки киеп йөрүче кызлар туңдырмаучы сыекча эчәләр.
- Операциядән соң күңеле нечкәргән авыру, хирургны кочып, аңа корсангында ялгыш калган скальпеле белән кадаган.
- Яңа елда ирләр модасының төп тренды – чиста носкилар.



Валерий ТАРАСЕНКО

ШОМБАЙ болай диде...



Хөрмәтле Чаян! Хәзерге Европаның әхлагы гаҗәпләндерүдән туктамый. Аларның «толерантлык» дигән нәрсәдән башларына зыян килгән, ахрысы. Кёльндагы Яңа ел мәхшәрен генә алыйк. Башта аны яшереп калырга маташтылар. Аннан соң бу вакыйганы матбугатта телгә алу тыелды. Шуннан соң немец хатыннары моны үзләренең тыйнаксыз кыяфәтләре белән китереп чыгарган, дип белдерделәр. Ә ахырда ачуы чыккан җирле халыкның демонстрациясен куып тараттылар...

Р. ХӘСӘНШИН

әлмәт

– Болай булгач, традиция буенча, килмешәк бандитларны «уртача көчләүчеләр» дип атыйсы гына кала, – диде Шомбай ага, укучының хатын укыгач.



Александр СЕРГЕЕВ

Искәндәр БОРҺАНОВ

ГЕОПОЛИТИК ГАЙБӘТЛӘР

Дәүләтләр, кешеләр шикелле, бер-берсен яраталар, күралмыйлар, хыянәт итәләр, мәхәббәт яулап алыр өчен көрәшәләр...

Инде илләр өчен дә дәүләт никахы кертергә вакыт.

Күз алдына китерегез: зур, бай Россия иртән киерелеп алды да, тирә-юненә күз салды: кияүләр белән ничек икән...

Көнбатышта олы яшьтәге тутәйләр – күп сөйләшүче Франция, тәкәббер Англия, картаеп килүче Германия, яшәреп торучы Италия... Өстәвенә, алар ирекле мөнәсәбәтләрне артык күрәләр...

Ә океан артында? Анда бай Америка, кайнар канлы Бразилия, көйдергеч Мексика. Алар тирәсендә чибәр, ләкин фәкыйрь Гондурас белән Сальвадор бөтереләә...

Ирләр Африкада да бар – Чад, Мозамбик, Нигер, тик алар нишләптер Европа хатыннарына тартыла...

Тагын Израиль бар, ләкин ул йә шәхси юрист, йә табиб буларак ярый...

Көнчыгышта ничек?

Янда гына Казакъстан һәм Үзбәкстан бар, тик бертуганнарга чыгарга ярамый...

Пакыстан гомер буе Һиндстан белән мөнәсәбәтләрен ачыклый, Иран белән Гыйракка Американың күзе төшкән...

Шулай итеп, Кытай кала – борынгы, эшчән, хәйләкәр, бала сөючән... Ләкин ул да Япониягә күз атып йөри бугай...


Бу тормышта таянырлык ышанычлы җилкә булмагач авыр шул!

Ә уйлап карасаң, үз җилкәң нык булганда башканыкы, бәлки, кирәк тә түгелдер...



Валентин ДУБИНИН


Вячеслав ШИЛОВ


Валентин ДРУЖИНИН

• • •

Заводка зур түрә килә һәм эшчеләр алдында икътисад турында чыгыш ясый:

– Моннан берничә ел элек алтын бәясе күтәрелде, ләкин бу халыкның тормыш ихтыяҗына тискәре йогынты ясамады. Аннан соң мех, автомобиль, кием-салым бәяләрен күтәрдек. Бу да халыкка зыян салмады. Тиздән азык-төлекккә дә бәяләрне күтәрергә уйлыйбыз. Минемчә, бу да...

Залдан тавыш:

– Ә сез агу сиптереп карамадыгызмы?

ИНТЕРНЕТ КАРАКЛАРЫ

Бөтенебезгә билгеле киносериал персонажы Шарапов кесә каракларын криминал баскычында иң түбән сорт дип фикер йөрткән. Ә тәҗрибәле Глеб Жеглов киресенчә – “карманник”ларны караклар арасында югары пилотаж ияләре дип санаган: “Аек акылда булган кешенең кесәсеннән сиздермичә акчасын шудырталар, ә аның колагы да селкенми – моның өчен нинди сәләт, нинди талант кирәк!”

Бүгенге “кул хезмәте” осталарына салкын акыл да, музыкаль бармаклар да, үткен йөзле пәке дә кирәкми. Алар бернинди хәвеф-хәтәрсез, тавышсыз гына акчаны кун бумажниклардан түгел, компьютер аша чыгаралар. Диваннан кузгалмыйча да...

Яңа ел бәйрәмнәре алдыннан Чаллыда берничә кешенең банк карталарыннан серле рәвештә акчалары юкка чыккан. Мәсәлән, баласын дәвалау өчен кредит алган 38 яшьлек Борис Н. акчасын бер картадан икенчесенә күчергән. Әмма бик тиз гаҗәпкә калган: аңа картасыннан 9 мең сум алыну турында SMS хәбәр килеп төшкән! Ул үзе бу акчаны күрергә дә өлгермәгән. Ә электрон караклар күргән. Әйтергә кирәк, узган елда гына мондый хәлләр турында полициягә 123 гариза килгән...

“Контактсыз” урлаулар ничек эшләнә соң? Көн саен елгыр мошенниклар яңадан-яңа ысуллар уйлап таба: ял итү клублары, банкоматлар, Интернет кибетләре аша. Иң таралган ысул – SMS хатлары тарату. Явыз уйлы җинаятьче булачак корбанының смартфонына зыянлы программалар кертә.Чираттагы өстәмә куелганда смартфон хуҗасының логин һәм паролен сорый. Бернинди шиге булмаган хуҗа мәгълүматларны турыдан-туры җинаятьчегә җибәрә. Менә ул әләкте дә! Хәзер аның логин белән паролен белгән җинаятьчегә электрон картадан акча күчерү бернәрсә дә тормый...

Шуны да әйтеп узарга кирәк, зыянлы программалар смартфонга уеннар, фильмнар, музыка яздырганда да эләгә ала.

Интернет аша урлау очраклары инде күптәннән теркәлә башлады. Менә аларның тик берничәсе генә. Санкт-Петербургта ике бертуган берничә банкның клиентлары счётларыннан 11 миллион сум күчергәннәр. Алар зыянлы программаларын “ватылган” сайтлар, SMS һәм спам аша тараткannар. 2014 елда полиция кулына “Фашист” кушаматы белән эшләгән кибер-мошенниклар төркемен тоткарлый. “V Рейх” дип аталган программа ярдәмендә “фашист”лар берничә банкның счётыннан 50 миллион сум алганнар. Тик “блицкриг” барып чыкмаган... Ә күптән түгел Түбән Новгородта тагын бер электрон “акча янчыкларын” бушатучылар төркемен тоткарлаганнар.

Мондый афәтләрдән ничек сакланырга соң? Киңәшләр гадидән-гади: гаджетларыгызга теләсә нәрсә яздырмагыз, төрле “призлы уеннар”да һәм “сорашулар”да катнашмагыз, логин һәм парольләр белән бүлешергә ашыкмагыз, антивирус программаларыннан файдаланыгыз. Уяу булыгыз.

Айдар СУБАЕВ







Валентин ДУБИНИН



Валерий ТАРАСЕНКО



Василий АЛЕКСАНДРОВ





• • •

Урамда тайгак. Барлык ирләр дә минем аяк астында ятачак дигән хыялым тормышка аша башлады. Менә әле генә, кибеткә барып килгәнче үк, икесенә торырга булыштым, берсе белән хәтта ятып та алдым!

• • •

– Син шимбә көнне нишлисең?

– Улым белән оча торган еланны һавага җибәреп уйныйбыз, ә син?

– Мин дә шулайрак планлаштырып торам: хатынның әнисен аэропортка озатам.

• • •

Килен булып төшәчәк кыз шулкадәр ямьсез иде, аны алып кайту өчен бик тәҗрибәле алыпсатар менеджер ялларга туры килде хәтта.

• • •

Кызлар колагына! Пенсия яше арттырылу сәбәпле, "Әле һаман җиләк" чоры 45 яшьтән 65 кә күчерелә.

• • •

Иренең туган көнендә хатыны аңа икенче бүлмәдән кычкыра:

– Мин сиңа искиткеч шәп бүләк әзерләдем, син аны хәтта нинди икәнен күз алдыңа да китерә алмыйсың!

– Алай булгач, күрсәт тизрәк!

– Хәзер, мин аны кия башладым инде!

• • •

– Беләсеңме, күршебез бит күчемсез милеккә хуҗа булган.

– Беләм, ул миңа зарланды инде, төнлә машинасыннан тәгәрмәчләрен салдырганнар.

• • •

– Назлыкаем, әйдә куркыныч фильм карыйбыз.

– Ярар, кершәнеңне сөрт.

• • •

– Сәлам, хәлләр ничек?

– Нигә сорыйсың? Бер илдә яшибез ич...

• • •

– Бездә кунакта атказанган морж. Беренче мәртәбә бәкегә ничек эләктегез, сөйләгезче?

– Шулай ук инде, башкалар кебек: юлны кыскартмак булып...

• • •

Ике ир сөйләшә:

– Мин аңардан акылымнан яздым.

– Соң, шул турыда сөйлә син аңа.

– Син нәрсә?! Ул бит психиатр.



Картриджда буяу бетте. Бүген зарплата булмаячак.

Яшь, вакытлыча эчмәүче ир кеше бер айга эш эзли.


Акча белән чемодан югалттым. Үтенеп сорыйм, акчасын булса да кайтарыгыз.

Кызыклы, мавыктыргыч эшкә йөк ташучы кирәк.


Африкадан килгән студентларга койрыкларын тапшырырга!

(Белдерүләр)

Виталий ФЕОКТИСТОВ



Алексей БУЛАТОВ



БЕР ФИКЕРГӘ – ИКЕ КАРАШ

Рашат Низами: 10 елдан соң, ниһаять, Ираннан санкцияләрне алдылар. Ә зуур Россияне санкцияләр белән чорнау галәмәте ничә елдан соң туктатылыр икән?

Алмаз Хәмзин: Кызыл кар яугач...

Р. Н.: Информацион сугышта туплар атмый, ядрәләр очмый, әмма бер ялган ун дөреслекне сугып егарга мөмкин!

А. Х.: Ялганга корылган дөньяда яшибез, Рашат дус. Шуңа күрә туплар да тынмый, дөреслек тә юк...

Р. Н.: Әгәр аткан ядрәләре “сөт”кә китә икән, андый мәргәнне сөт җыючы итеп билгеләргә генә кала.

А. Х.: Безнең илдә нәкъ шулай: ваучерлаштыру идеологын да, СССРны таркатучыларны да, “Оборонсервис” җитәкчелеген дә уйлап әйтәсеңдер инде...

Р. Н.: Сталинның наркомнары сәяси “Наркоман” булган дисәк, дөрес булырмы?

А. Х.: Нигә Сталинныкы гына? Гомумән, сәясәт – изге нәрсә түгел һәм анда катнашучылар да...


Р. Н.: Теләсә кайсы чиновник көннәрнең берендә “капкын”га эләгергә мөмкин.

А. Х.: ...Булешмәгән очракта...


ЯШӘГӘН, ДИ, БЕР РӘССАМ...


Валентин ДУБИНИН

Дмитрий КОНОНОВ




Александр СЕРГЕЕВ



Валерий ТАРАСЕНКО

• • •

Яшь рәссам натурщицаны үбеп ала.

– Син бөтен натураларны да шулай үбәсеңме? – дип сорый тегесе.

– Юк, син беренче.

– Ә алар синең күп булдымы соң?

– Дүртәү: селедка, алма, суган һәм син.

• • •


Рәссам остаханәсендә берәү заказ ясарга тели:

– Сез миңа май белән эшләнгән арзан гына нәрсә тәкъдим итә аласыз?

– Бер банка ставрида!







Виталий ПОДВИЦКИЙ



Валерий ТАРАСЕНКО

Алмаз ХӘМЗИН

ТӨРТТЕРЕП СӨЙЛӘШҮ

Разил Вәлиев җан дус бит инде. Бер авылда үстек, бер сыйныфта укыдык, бер партада утырдык. Гомумән, язмышлар да бертөслерәк. Разилнең инде күп мәртәбә Татарстан Дәүләт советы депутат булып сайлануында минем дә, печтик кенә булса да, өлешем бардыр дип уйлыйм.

Шул, сайлаулар җитүгә, депутатлыкка кандидат итеп күрсәтелгән дустым белән, “сайламасалар, ичмасам, халык күңелен ачып йөрербез” дигән лозунг астында, концерт-пропаганда оештырып йөрибез. Беренче тәҗрибәбез Казан шәһәренең “Дуслык” бистәсендә башланып китте. Мин төннәр буе “Депутатлыкка кандидат, шагыйрь Рәзил Вәлиев белән фәлән-фәлән урамда очрашу-концерт була” дип, белдерүләр язып, шуны коймаларга, баганаларга ябыштырып йөрим. Игътибар иткәнсездер: “Разил” дигәндәге “а” хәрефен “ә” белән язып. Шулай иткәндә исеме үзебезчә, татарча һәм дә ягымлырак әйтелә кебек. Беркөнне Разил минем янга килеп, кыймыйчарак сүзен башлады.

– Нишләп син мине “Рәзил” дип язасың? Мин бит сиңа Әлмәс дип эндәшмим, – ди.

Бар инде аның шулай төрттереп әйтә торган чаклары.

Нияз-БИШБАЛТА

ХАЛЫК ҖЫРЛАРЫНА ИЯРЕП...

Уйна, дустым, гармуныңны
Без җырлаган көйләргә,
Торгынлык еллары безгә
Калды сагынып сөйләргә.

Каз канатлары ак була,
Ир канаты ат була;
Бераз пинсе күтәрсәләр,
Карт-корылар шат була.

Тал әйләнә, тал әйләнә,
Талга ефәк бәйләнә,
Кибеттәге бәяләрне
Күргәч, башлар әйләнә.

Сирень чәчәк аткан чакта
Яратам сирень исен.
Оят качты бай түрәдән,
Онытты чама хисен...

Зәңгәр чиләк матур була
Су белән тулса гына.
Җитәкчене халык мактый
Сүзендә торса гына.

Су буенда кыяк үлән,
Кыеп аласы иде,
Бәя буып үтергәнче
Яшәп каласы иде.



Максим СМАГИН



Александр АЛЁШИН



Игорь КИЙКО



ТОТКЫННАР һӘМ МИЛЛИОННАР

Нинди генә рейтинглар, сораштырулар, исемлекләр юк хәзер массакүләм мәгълүмат чараларында! Менә "РКБ" порталы бәясе миллион ярым сумнан артыгрык булган машинада йөрүче чиновниклар һәм башка халык турында кайгыртучыларның исемлеген дөньяга чыгарды. Бу исемлектә безнең республика җиденче урында тора. Экспертлар белдерүенчә, безнең юлларда уртача бәясе өч миллион булган алтмышлап "алтын арба" йөри. Бигрәк тә тугызынчы номерлы хезмәт белән төзәтү колониясе балансында торган машина гаҗәпкә калдырды. "Җәза башкаручылар"ның мәнфәгатьләре өчен 4,5 миллион сумлык "Мерседес S320" алынган булган.

ҮТКЕР АКЫЛ

Безнең халыкның башы шәп эшли. Бигрәк тә кризис вакытында. Бу юлы Рәсәй кешесенең үткер акылы кредитлар буенча түләмәү ысулы уйлап тапкан. Якутиядә яшәүче берничә кеше ФСБның җирле идарәсенә гариза язган. Анда алар кредит алган чакта банкның учредителе чит ил компаниясе булуы турында белмәүләре турында белдергәннәр. Чөнки кредит түләгән заемщиклар турыдан-туры чит дәүләткә финанс ярдәме күрсәтү статьясына барып эләгәләр. Контрразведка хезмәткәрләренә хәзер бу гаризалар белән нәрсә эшләргә дип баш ватасы гына кала.

ДИҢГЕЗ БУЕ ДЕМОГРАФИЯСЕ

Европа тарафыннан гаиләнең җәмгыять күзәнәге булуын инкарь итү беренче җимешләрен китерә башлады. Даниядә, мәсәлән, Скандинавия илләре арасында иң түбән туучылар саны. Бу мәсьәләне монда бик үзенчәлекле ысул белән чишәргә тырышалар. Туристик компанияләрнең берсе белән берлектә олы яшьтәге хатыннарга җиткән балалары өчен эссе илләргә зур ташламалар белән юлламалар тәкъдим итү программасы эшли башлады. Җылы һава, диңгез һәм яшьлек дәрте егет-кызларга якынлашып, гаилә парлары төзергә һәм, нәтиҗәдә, бала табарга ярдәм итәр дип фаразлана.

Рәфгать РЫСАЕВ

ШУНДЫЙ МИЗГЕЛ БЕЗНЕҢ

Ашыктырма әле, ашыктырма,
Салкын кыш бит тора ишектә.
Ашкынулы ярсу хисләр шавын
Тик язларда колак ишетә.

Безнең ташкын чаклар, ни үкенеч,
Ярларына кайтты бик күптән.
Гомернең бит язы бирәү генә,
Урап кайтыр язы юк бүтән.

Кыш елгалар боздан толып киеп,
Ашыкмыйча ага тын гына.
Шундый мизгел безнең – янмый-көйми
Яшәп ятар вакыт шым гына.

Ашыкмыйча елга тын акса да,
Кояр урынына җитә бит.
Ашыктырма әле, җайсыз димә,
Ярый бергә без, дип, шөкер ит.

• • •

Купеда ике ханым белән бер солдат бара. Кич җиткәч, солдат, итеген салып, аяк чолгауларын киштәгә элеп куя. Купега түзә алмаслык ис тарала.

– Солдат, син аяк чолгауларыңны алыштырасыңмы? – дип сорый ханымнарның берсе, нәфрәтләнеп.

– Юньле әйбергә булса, алмаштырам! – ди солдат.

Василий АЛЕКСАНДРОВ





ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР...

Сәнгатькә бөтен гомерен бирде, ә ул һаман исән!

Начар характеристика яхшы некрологтан шәбрәк.

Илһам шагыйрьгә еш килә иде, тик беркайчан да аны урынында тота алмады.

Үз даның йокларга комачаулый, ә кешенеке – йоклап китәргә дә бирми.

Минем матди муллыгым гомер буе рухи байлыгымнан көнләшеп яшәде.

Бер китаплар безне яшәргә өйрәтә, икенчеләре көндәлек тормышыбызны бизәп тора.

Талант язмыйча, ә графоман басылмыйча яши алмый.

Кайбер артистка зал алкышларга күмелсен өчен сәхнәдән китү җитә.

Бөек идеяләр алар өчен үлчеләр булганга яши.

Шуышып йөрергә ияләнгән халыкны тизләндерү мөмкин түгел.

(Зыялылар мәҗлесендә язып алынды).







Рашат НИЗАМИ

ҺӘЙКӘЛ

Шаккатамын һәм тел шартлатамын:
Район саен – танк һәйкәле.
Нигә, нигә трактор дустыбызга
Һәйкәлләр юк – шуны әйт әле!..

РӘНҖҮ


Кая гына барып оя корсын,
Кай агачка барып кунаклар?
“Китмә, китмә, сандугач...” дип җылый
Киселмичә калган куаклар.

ЯЛВАРУ

Яңгыр явып узган юл читендә –
Поши тоягының эзләре...
“Син кем, егет, аучы түгелме?” – дип,
Карый миңа урман күзләре.

МӘХӘББӘТ

Мәхәббәт ул, әйе, бик борынгы,
Миллионнар
Үз йолдызын тапкан дөньяда...
Мин ананып әйтәм: искермәгән –
Сөю бит ул мәңге өр-яңа!







СӘЛАМӘТ БУЛЫГЫЗ!

Кадерле Чаян! Минем сәламәтлегем турында кайгырткан телевизионщикларны күреп, күңелем нечкәреп киткәнен сизми дә калам кайвакыт. Юк, Елена Малышева һәм дәва-шифа тия торган тапшырулар турында әйтүем түгел.

Әйтик, күп кеше телеэкраннарга ябырылган вакытта, кан койгыч сериаллар бара: гадел хокук саклау органнары хезмәткәрләре явыз бандитларны тотып манчый, яисә, киресенчә, акылдан шашкан полиция хезмәткәрләрен игелекле бандитлар акылга утырта. Анда сугыш, атыш, кан коеш... һәм кисәк кенә экранда шундый язу пәйда була: “Кадерле тамашачылар! Алдагы сюжетта тәмәке тарту эпизоды булырга мөмкинлеген кисәтеп куябыз. Тәмәке тарту сезнең сәламәтлеккә зур зыян китерә!”

Билләһи, синең сәламәтлек турында кемнеңдер борчылуын күргәч, елап җибәрерсең...

Н. БУЛАТОВА

АЗНАКАЙ

ТЕГЕНДӘ-МОНДА ТӨРТЕШ...

Хөрмәтле редакция! Советлар чорыннан ук инде без чират торуларга күнеккән һәм чыныккан. Безне чират белән генә куркыта алмассың. Ә менә сәламәтлеге чикләнгән пенсионерлар өчен дәвалану һәм ял итү учреждениеләренә юллам алыр өчен чират тору минем хәлдән килми шул. Күпсанлы ял итәргә теләк белдерүчеләр дә тилмерә бу хәлгә.

Элек сәламәтлеге чикләнгән пенсионерларга хезмәт күрсәтү белән Россиянең Татарстан күләмендә социаль иминият фонды шөгыльләнә иде. Мин барлык документларны җыеп чиратка бастым. Күпмедер вакыттан соң, мондый хезмәт күрсәтү халыкны социаль яклау органына тапшырулары билгеле булды. Ни сәбәптәндер, чират сакланмаган. Кирәкле кәгазьләрне яңадан җыярга һәм яңадан чиратка басарга туры килде.

Күптән түгел чиратны белешеп, юлламаның кайчан булачагы белән кызыксынып алырга булдым. Мине тагын чираттагы сюрприз көтә иде. Баксаң, льготниклар белән яңадан социаль иминият фонды шөгыльләнә башлаган. Әлбәттә, чират тагын сакланмаган...

Әлеге хезмәтнең тегендә-монда күчүе безгә һич аңлашылып бетми. Шунысы ачык: димәк, ясалма рәвештә китереп чыгарган табигый сайланышта бик күпләр коелып кала, бары сәламәтлеге нык, чиратларга бирешми торганнар гына юллама алу бәхетенә ирешә ала.

М. САБИРОВ

КАЗАН




Виктор ФЁДОРОВ



Эрнест ДЫШАЕВ

Виктор ФЁДОРОВ



Александр КОСМЫЛИН



ИЛ ҺӘМ БАКЧАНЫҢ КЫСКАЧА ТАРИХЫ

1937 ел. Тормыш күңеллерәк булып китте. Папанин котып бозларында. Чкалов Төньяк полюс аша Америкага оча. Бөтен ил «Кыска курс»ны укый. Массакүләм утыртулар башлады. Кыш көне ашамасалар, яз көне утыртырлар. Монысы инде бәрәңге турында. Шәһәр кешеләренең бакчалары булмау кызганыч. Доллар – нәрсә ул?

1947 ел. Бөтенхалык хуплавы белән акча реформасы үткәрелде. Карточкаларны бетерделәр. Утыртулар дәвам итә. бер уч башак өчен биш елга утырырга була. Утыртасы килә, бу бәрәңге турында. Доллармы? Ул Америка акчасы бугай. Их, үз бакчаң булса иде!

1957 ел. Халык шатлыгыннан нишләргә белми! Космоска көчек җибәргәннәр. Мәскәүдә – Бөтендөнья яшьләр фестивале. Бөтен ил буенча «хрущёвка»лар төзи башладылар. Халыкка бакча өчен җир бирә башладылар. Утыртулар бетте. Бу бәрәңге турында түгел. Доллар стилягалар һәм спекулянтлар арасында бик популяр.

1967 ел. Ил куана! Яшьләр «Битлз»дан акылыннан яза. Хатын-кызлар – Магомаевтан, ирләр – мини-юбкалардан. Бөтенесе твист бии. Бакчалар белән катлаулыклар. Кукуруза безнең җирдә үсми. Алмагачларны салымнар аркасында кисеп аттылар. Бәрәңгегә рәхмәт, тагын коткарды. Капрон оеклар һәм кримпленны бары тик долларга гына алып була.

1977 ел. Яшьләр «хиппи» булып йөри. Картлар сукрана. Радиодан – Пугачёва. Телевизордан – Политбюро. Урамнарда машиналар юк диярлек. Аның каравы, адым саен кызыл повязкалы дружинниклар. Буш кибет киштәләре һәм чиратлар. Җире булганнарга рәхәт! Доллар курсы беркемне дә кызыксындырмый. Иң мөһиме – партия курсы!


1987 ел. Үзгәртеп кору. Эчкечелек һәм виноград агачлары белән көрәш. Ирек, демократия котырына. Бөтен нәрсә талоннар буенча. Көн саен яңа партия теркәлә. Ачык курс урынына – борылмалы-сикәлтәле юл. Илнең хуҗасы – доллар, төп туйдыручы – алты сутый җир.

1997 ел. Ил белән либераллар һәм реформаторлар идарә итә. Көн саен, понимаш, документлар белән эшләү. Ваучерлар һәм приватизация. «Пирамида»лар һәм кыркылган башлы «браток»лар. Милиция күренми. Бөтен җирдә «олигарх» сүзе яңгырый. «Крутой»лар гади халыкны санга сукмый. Доллар милли валютага әйләнә. Һәр кеше үз бакчасында капитализм төзи.

2007 ел. Доллар курсы һәм нефть бәясе – төп яңалыклар. Олимпиада Сочида булачак! Сайлауларда «бөтенесенә дә каршы» графасы юкка чыгарыла. Авыл хуҗалыгы дәүләт ярдәменнән башка үлеп бара. Ярый әле, бакча бар!

2017 год. Алда безне нәрсә көтә? Кризисмы? Әллә стабилизацияме? Нәрсә булса да, бердәнбер котылу чарасы – бакча! Һәр казылган түтәл – кризисны бетерүгә синең керткән өлешең. Банкаларны җиләк-җимеш белән тутырыйк. Базга капчык-капчык бәрәңге салыйк!

Тарихны Нәҗия БӘХТИЕВА язды.



Татарстанның халык артисты, атаклы баянчы Рамил Курамшинны белмәгән татар бармы икән? Юктыр! Булса да, милләт язмышы, әдәбият-сәнгать белән бөтенләй кызыксынмаган кеше генә булуы мөмкин. Рамил Курамшин – милләтебезнең горурлыгы, йөзек кашы ул! Өздереп баянда уйный, бары тик халык күңелендә урын алырдай көйләр генә иҗат итә, газета-журналлар битләрендә әдәбият-сәнгать мәсьәләләренә кагылышлы җитди, үткен мәкаләләр белән чыгышлар ясый, тарихыбызны барлый.

“БЕЛМӘСӘҢ, БЕЛ!”

Алтмышынчы еллар азагында Казанга гастрольгә Ленинград җырчысы Эдуард Хиль килә.

Хәләл җефете:

– Хиль концертына билет алып кайт инде! – дип интектерә башлагач, бас тавышлы җырчы Генрих Дәминов:

– Янында Шаляпин йөри, ә син нинди дер Хиль белән баш катырасың, – дип тегене тынычландыра. Һәм шулай итеп, үзен билет алу мәшәкатеннән коткара.

ТАНЫШУ

Мәҗлестә берәү Нәҗип Җиһанов белән таныша:

– Фәлән Фәләнов – завод директоры. Телевизорлар, суыткычлар чыгарабыз!

– Нәҗип Җиһанов – композитор. Опералар, симфонияләр чыгарам...

ТИЛЧӘ

Нәҗип Җиһановның “Җәлил” операсын тыңларга килгән Усман Әлмиевнең урыны бик сөйләшергә яратучы бер тилчә ханым янына туры килә. Спектакль буена сөйләшүе белән интектергән бу ханым, тамаша тәмамлангач, тәкъдим ясый:

– Усман абый, тиздән “Алтынчәч” тә була! Бәлки, аны да бергә карарбыз?

– О, бу бик кызык булачак! Мин бит сезне “Алтынчәч”тә бер дә ишеткәнем юк әле...

ДАҺИЛАР

1952 ел. Гастрольдә йөрүче филармония артистлары буш вакытларында гәп корып утыра. Сүз даһилар темасына кереп китә. Байтак фикер алышкач, болар өч даһины тәгаенлиләр: Карл Маркс, Ленин һәм Сталин. Сүзгә кушылмыйча гына бер читтә көлемсерәп торган баянчы Фәйзи Садыйков шулчак болай дип куя:

– Җәмәгать, әле тагын бер даһи бар бит – ул Мөхәммәд пәйгамбәр! Чөнки дөнья халкының яртысы диярлек мең елдан артык инде аның кануннары белән яшәп ята лабаса!


Тегеләрнең күзләре шардай була. Ул заман идеологиясе өчен Фәйзи аганың бу сүзләре бомба шартлагандай яңгырый...

Валентин КОСМЫЛИН, «Чаян» № 10, 1974



– Сез шикаять беләнме?
– Юк, мин аны кире алам – минем түшәмнән генә тама...

Эрнст ГЕЛЬМС, «Чаян» № 7, 1962



Кайдадыр Көнбатышта.
– Әби, синең тормышың страховать ителгәнме?

Сак булыгыз, балалар!

• • •

– Балагызны бер-ике атнага балалар бакчасына биреп торыгыз.

– Нигә?

– Ул чакта сез аның бу сүзләрне каян өйрәнгәнен аңлата алырсыз.

• • •

– Әти, ә син беләсеңме, нинди поезд барыннан да күбрәк тоткарлана?


– Нинди, улым?

– Син узган Яңа елда миңа бүләк итәм дигәне!

Александр СЕРГЕЕВ



Виктор БОГОРАД



Виктор ФЁДОРОВ





ЧуАр пресса

КАР ЯВА

Түбәннән бер "FM" радиостанциясендә "Руки вверх" группасының яңа җырын уйнатканнар. Хитны тизрәк популярлаштыру өчен, күрәсең, "Королева красоты" җырын эфирда 40 мәртәбә рәттән яңгыратканнар. Ачулары кабарган радио тыңлаучылар шалтыраткач, радиостанция җитәкчеләре гаеплегә җәза биргәннәр һәм урамга кар чистартырга чыгарганнар. Мондый җәза беренче генә очрак түгел. Австралиянең радиостанциясендә эшләүчегә 24 мәртәбә Last Christmas җырын уйнаткан өчен Яңа ел бәйрәмнәрендә эшкә чыгарга мәҗбүр иткәннәр.

ПРАВА


Мәскәүдә яшәүче Андрей Филин правага гаҗәп баш киеме белән – дуршлаг рәвешендә бәйләнгән башлык киеп фотога төшкән. Гаишниклар, автомобиль йөртүченең юмор хисен бәяләп, аны шул баш киемен машина йөрткәндә кияргә мәҗбүр иткәннәр.

Андый-мондый, Андрей руль артында башлыксыз булса, аның правасын алачаклар.

ИТАЛЬЯННАРНЫҢ РОССИЯДӘ ЯҢА МАҖАРАЛАРЫ

Петербургта Италия мафиозие Никола Ди Муроны кулга алганнар. Сицилиянең Коза Ностра әгъзасы җинаятьне Италия территориясендә эшләсә дә, аның эшләре Россия законнары буенча да җәзага лаек. Мафиозиның адвокаты сак астында тотуны өй арестына алыштыруны сораган. Аның сүзләре буенча, Ди Мауро тикшерүдән качып йөрергә җыенмый – төрмәгә эләксә элә, әмма Россия гражданлыгын алырга җыена.

Анатолий РАДИН





Николай ВОРОНЦОВ




РЕКЛАМА

2016 елның беренче артыеллыгына язылу дәвам итә.

Журналның индекслары
татар телендә – 73488,
рус телендә – 73489

Интернетта безнең сайт: chayan-journal.ru

КҮҢЕЛЛЕ КУНАКЛАР



Чит ил басмаларыннан шаян рәсемнәр

ПАНЧИТО (Бразилия)





Карлос ЛАТУФ (Бразилия)



Анхель БОЛИГАН (Куба)

Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

Барыбер дөнья яхшыга таба үзгәрә. Хәзер кешеләр кибеткә керү белән “Исәнмесез!” диләр. Ә элек, мин бәләкәй чакта, “Кем актык?” дип әйтәләр иде.

• • •

Хакимиятнең ришвәтчелек белән көрәшүгә хәйләкәр планы бар, ахрысы: түрәләргә ришвәт бирмәс өчен халыкның, хәерчеләнеп, бер тиен акчасы да калмаска тиеш.

• • •

Безнең футбол җыелма командасы читтә һәрвакыт начар уйный, чөнки андагы яңа капканың матурлыгы күзләрен камаштыра.

• • •

Ике опер (җитез работник) дежурныйга шалтырата.

– Нәрсә анда сезнең?

– Үтерешкә охшаган хәл, хатын иренең башына сигез мәртәбә таба белән бәргән.

– Ни өчен?

– Тегесе әле генә юган юеш идәндә йөргән өчен. Ир хастаханәдә.

– Хатынын тоткарладыгызмы соң?

– Юк, идән һаман юеш бит әле.

• • •

– Нигә син мине гел җүләргә саныйсың?

– Нигәме? Чөнки мин әзер материал белән эшлим.

• • •

– Алло! Бу базамы? Мин сарай мәсьәләсендә шалтыратам.

– Гафу итегез, ләкин бу ракеталар базасы. Сез ялгыш эләккәнсез.

– Юк, сез үзегез ялгыш бомбить итәсез.

• • •

Яңа диета: өстәл артына ашарга утырганчы, идәннән кулга таянып, арганчы этәреш ясарга кирәк. Беренчедән, ашыйсы килми башлый; икенчедән, куллар калтырый, ә алай әллә ни күп ашап булмый.



ЧАЯН (СКОРПИОН)
САТИРА һәм ЮМОР ЖУРНАЛЫ
№ 2 2016

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры һәм баш редактор
Рафаэль ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш редактор урынбасары: **Ринат АБЗАЛОВ**
Баш редактор урынбасары, баш рәссам:
Александр АЛЁШИН
Үсеш бүлеге: **Әдилә БАҺАВЕТДИНОВА**
Марс САБИРОВ
Җаваплы секретарь: **Гөлнара ЗАМАЛДЫНОВА**
Бүлек редакторлары: **Людмила САФИУЛЛИНА**
Артём СУББОТКИН
Алмаз ХӘМЗИН
Лилия ӘХМӘТОВА
Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: **Ләйсән ФӘЛӘХОВА**

УЧРЕДИТЕЛЕ: «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итүче Федераль служба (Роскомнадзор) идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты: Эл № ФС77-61789, 18 май, 2015 ел.
Нәшер итүче: **АО «ТАТМЕДИА»**
Адрес: 420047 Казан, Академическая ур., 2
Редакция фикере авторлар фикере белән тәңгәл килергә мөмкин.
Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.
Реклама белдерүләренең дөреслеге өчен реклама бирүче җаваплы.
Басма 16 яшьтән өлкәнрәк укучылар өчен чыгарыла.
«Чаян»нан икенен күрсәтмичә журнал әсәрләрен файдалану тыела.


татмедиа
Белешмәләр өчен телефоннар:
(843) 222-06-00,
тел./факс: 222-05-54.
16+
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan.su
Редакциянең адресы: Декабристлар ур., 2, ТР, Казан, 420066

Рөстәм ЗАРИПОВ

УТЫРЫП ТОРУ

Төштә дә яшәү дәвам итә. Әле ничек кенә итә... Мәскәүдә, шактый дәрәҗәле урынга үрмәләгән сабакташым күрсәтмәсенә буйсынып, җөмһүриятебезгә баш казаначымы, финанс министрымы итеп билгеләгәннәр. Макулатура җыю ноктасында бухгалтер вазыйфасыннан менә шундый сикереш ясаганмын, инәңнең коерыгы...

Яңа түрә, ягъни мин килешкә кызыл келәмне урамга ук чыгарып түшәгәннәр. Башына каракүл бүрек кигән, ак мыеклы, калын пыяла күзлекле таныш та сыман берәү шунда таптана.

Яшерен-батырын түгел, мин хисапчы булып эшләгән макулатура пунктына чималны олау-олау ташып кына торалар. Китергәнне исәпкә алучы дәртле Хәтирә балдыз, буяу исе килеп торган кайсыларын китапханәләргә кертеп чыгарып, кайсыларын кертеп тә тормый, туп-туры китереп бушаталар, дип шыттырырга ярата... Шәхсән үзем әдәбиятка дөм битараф кеше түгел түгелен, китапларның алгы битләрен ачып, авторларның фотоларын булса да караштырып барам.

Анысы да монысы, яңа эш урынымдагы секретарша туташ күңелгә хуш килде. Сезгә ялган, миңа чын, төз, матур аяклары, кем әйтмешли, колакларыннан үскән. Кабинет дисәң кабинет, мәйданы егерме биш сутыйга гына бетмәс. Ул да булмый, ишектә күз күргән зат күренә...

– Рөхсәтме, иптәш Галиәхмәтов? Мондый урынга да китап кадерен белә торган зыялы кешене куярлар икән, – ди бу, авызын беткәнче ерып. – Кабинетыгыз үзегезгә үлчәп теккән сыман Мөгътәсим Шәрифулыч, игелеген күрергә язсын!

– Бергә бергә күрик. Узыгыз, утырып торыгыз.

– Сезнең кебек язучылар булмаса, мин бу дәрәҗәгә ирешми идем! Әйтегез теләгегезне! Оялып тормагыз! Сорагыз!

– Нибары бер миллиард кына сум акча кирәк.

– Тагын томнар чыгармакчы буласыз алайса? Әсәрегез ни атлы, әгәр сер булмаса?

– "Татар гаме". Күләме сиксән томга сыеп бетәр төсле.

– Ай-һай, зур эшкә алынгансыз.

– Афоризмнарга чират җитте, дип тора идем. Саруларын кайнатып чыгарганчы шулар белән дөңгечләргә исәп. Хезмәтем кырыкмаса кырык бүлектән торачак. Әйтик, беренчесе – космик төшенчәләр турындагысы, "Күк күк инде ул", "Җир җир инде ул", "йолдыз йолдыз инде ул", "метеорит метеорит инде ул" кебек сәйләннәрдән тезеләчәк.

– Калганнары?

– Алары да шул рухта... Әйтик, "балта балта инде ул", "сәнәк сәнәк инде ул" кебекләре эш кораллары дигән баш астына карый. Йорт хайваннары дигәненә "сарык сарык инде ул", "ишәк ишәк инде ул"лар туплана.

– Бухгалтер бухгалтер инде ул, депутат депутат инде ул, прокурор прокурор инде ул ишеләр дә сырланачакмы?

– Сорап торасыз!

– Ә җитәкчеләргә урын түрдәндер ич томнарыгызда?

– Әлбәттә. Кайбер чит ил эшлекләләрен дә кертми ярамас. Әйтик, "Буш – Буш инде ул", "Барак барак инде ул", дип белдерүләрдән кемгә зыян? Аннары чират җитә аtaклы футболчыларга, кәшәкә сугучыларга, тренерларга, йолдыз артистларга, генераль директорларга, генералларга, судьяларга... Аннары тән сакчыларына, кутюрьеләргә, дизайнерларга. Аннары инде галим-голәмә, укытучы-мукытучы, табиб-мабибларны, мөфти-фәфти, хәзрәт-мәзрәтләрне дә үпкәләтү килешмәс. Язучыларыгызны да онытып калдырмабыз, Корбан Корбан инде ул, Зәкуан Зәкуан инде ул, дип очлыйм ул "кибән"не!

– Шул ысулда калган җитмеш тугыз том тулыр дип саныйсызмы? Татарча-русча сүзлек тә бер генә том түгелме соң?

– Ите сезгә, сөяге миңа...

Моның гозеренә имза салыйм, дип кенә торганда, кабинетыма рөхсәт-фәлән сорамый, һәрбиләргә хас елгыр ике әфәнде килеп керә. Өстәлемә ыргыткан кәгазьләренә караганда, яңа вазыйфага мине түгел, ә минеке сыман исем фамилияле Фәлән Фәләнечнең тән сакчысының туганнан туганын раслаган булганнар, имеш. "Ошибочка вышла", диләр һәм кунак булмәм аша арт ишектән чыгып таярга киңәш итәләр. Карышсам, булышырга да вәкаләтләре бар, янәмәсе...

– Стоп, – минәйтәм. – Сабыр итегез, әфәнделәр, галстугыгызга баса күрмәгез. Менә бу абыегыз сиксән томлык китап чыгару ниятендә, миллиард сорый. Сезне куш куллап соавторлар итеп өлешкә алам, дип тора. Шулаймы, язучы әфәндем?

– Әлбәттә, гел, һәрвакыт шулай, – ди язучы әфәнде, чүгә-тора.

Егетләрнең ирен читләренә көлемсерәү йөгерә. Сизеп торам, уртак фикергә килү ихтималы юк түгел...

Берара, Тукай әйтмешли "күзгә күзне нык терәп", елмаешып торабыз. Сизәм, алар мине, мин аларны аңлыйм шикелле.

– Безне соавтор ясап, үзең чиста калмакчымы? – ди икенчесе, капылт кырысланып.


– Минем өчен кайгырмагыз, туганкайлар, макулатура склады хатын исемендә, абзагызга өлеш шуннан ага, – дип тынычландырам уяу егеткәйне.

– Акыллы кешегә охшагансыз!


– Үзегез дә төшеп калганнарга охшамагансыз, – дип, җиңел сулыш алырга өлгермим, будильник чылтырап, чәчрәп торып утырам. Эх, – минәйтәм, – Тагын кәгазь тузаны иснәргә барасы бит инде... Әгәр шул мәлгунь чылтырамаса, һичьюгы бер-ике сәгать булса да текә кәнәфидә утырасы, рәхәтен күрәсе, әллә нәрсәләр майтарасы идем...

Уйна да, уйла да!

ЧАЯНВОРД



Ринат АБЗАЛОВ төзеде.



1. Колагыңа токмач элүче, ягъни күзгә төтен җибәреп алдаучы ир белән нишләргә кала?

2. "Бик исертми торган эчемлек" нәрсәне аңлата?

3. Нәрсә ул сигарета?

4. Елның иң кыска көне?

5. Мәхәббәт белән сексның аермалыгы нәрсәдә?

6. Грузин белән әрмән русча кайда ызгыша?

7. Ире хыянәт иткән хатынны ничек дип атыйлар?

ЖАВАПЛАР

1. Мөгезенә шул токмачны урарга, ә шулпасын күзенә сибәргә. 2. Әлеге эчемлек йомшак алкоголиклар өчен. 3. Бу – бер башы утлы, икенчесе утерә торган таякчык. 4. Беренче гыйнвар. 5. Мәхәббәттә картлык киртә түгел... 6. Украинаның Реформалар буенча Милли совет утырышында. 7. Тол.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда ике җыр исемнәрен укыгыз. Журналыбызның 24 нче санында басылган чаянвордның тикшерү сүзләре – **«СӘРВИНАЗ»,** **«МӘДИНӘКӘЙ».**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

Ә. ГАРИПОВА (Әлки р-ны, Иске Салман ав.),
Р. ЗАҺРИЕВ (Кукмара р-ны, Югары Арбаш ав.),
Р. ИШМОРАТОВ (Арча р-ны, Урта Сәрдә ав.),
М. МИҢНЕМУЛЛИНА (Балтач р-ны, Норма ав.),
Д. НУРГАТИНА (Алексеевский р-ны, Урманасты Шонталасы ав.),
С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан).

Җиңүчебез – Казаннан **Сәгъдулла ШӘЙХУЛЛИН!**

Карикатура осталары


Родригес ГОНЗА (Бразилия)

Бразилия карикатурачысы Родригес ГОНЗА үз илендә генә түгел, бөтен дөньяда дан казанган рәссам. Чын бразилияле буларак, ул иҗатының төп темасы итеп футболны сайлаган. Шулай ук кино һәм сәясәт йолдызларыннан да шаяртып куя. Сезнең игътибарыгызга аның берничә эшен тәкъдим итәбез.



Жерар ДЕПАРДЬЕ


ПЕЛЕ


Майк ТАЙСОН


Роман АБРАМОВИЧ


Криштиану РОНАЛДО